ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

« 22 » апреля 2022 ел

№ 304

**«Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2018 елның 30 гыйнварындагы 75 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль берәмлек учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү системасын камилләштерү максатыннан, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль берәмлек хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) II бүлекнең 8 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә.

«8. Дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматлар белән эшләгән, аларны яшергән һәм ачкан, шулай ук шифрлар белән эшләгән өчен өстәмә түләү.

Даими нигездә дәүләт серенә кертелгән хезмәткәрләргә дәүләт серен тәшкил иткән белешмәләр белән эшләгән өчен айлык процент өстәмә түләве «Даими нигездә дәүләт серенә кертелгән гражданнарга һәм структур бүлекчәләр хезмәткәрләренә дәүләт серен саклау буенча социаль гарантияләр бирү турында» 2006 елның 18 сентябрендәге 573 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә түләнә.

| Айлык процент өстәмә түләве | Өстәмә түләү күләме (процентларда) |
|---|---|
| «Аеруча мөһим» яшеренлелек дәрәҗәсенә ия булган белешмәләр белән эшләгән өчен | Акчалата түләүнең 50-70% ы |
| «Үтә яшерен» яшеренлелек дәрәҗәсенә ия булган белешмәләр белән эшләгән өчен | Акчалата түләүнең 30-50%ы |
| Тикшерү чараларын үткәреп, рөхсәт формалаштырганда «яшерен» яшеренлелек дәрәҗәсенә ия булган белешмәләр белән эшләгән өчен,<br>тикшерү чараларын үткәрмичә | Акчалата түләүнең 10-15% ы<br>Акчалата түләүнең 5-10% ы |
| Дәүләт серен саклау буенча структур бүлекчәләрдә эш стажы өчен:<br>1 елдан 5 елга кадәр | Акчалата түләүнең 10 %ы |
| 5 елдан 10 елга кадәр | Акчалата түләүнең 15 %ы |
| 10 ел һәм аннан күбрәк | Акчалата түләүнең 20 %ы |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы сайтында (arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Р.Д. Шагиәхмәтов